| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.10.2024 Бима авылы № 58-1

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елның 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Бима авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләүгә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә карар кылды.

2. Салым ставкаларын түбәндәге зурлыкта билгеләргә:

1) 0,1 процентка карата:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнары;

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

20,2 процентка карата:

квартиралар, квартираларның өлешләре, бүлмәләр;

3) 0,3 процентка карата:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

4) 1,2 процентка карата:

-Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы билгели торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар;

5) 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

6) 2,5 процентка карата:

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары;

7) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

3. Бима авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- «физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 елның 36-1 номерлы;

- 29.12.2018 елның 46-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 елның 36-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 07.02.2020 елның 57-3 «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 елның 36-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

- 07.09.2022 елның 22-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 10.11.2014 елның 36-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"

4. Әлеге карар аны игълан иткән көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасы 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булуын билгеләргә.

6. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасының гамәлдә булуын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы

Совет Бимского сельского поселения — Бима авыл җирлеге Советы — ИНН 1601002621

Э.И. Михайлов